ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ
ВТ
№ 6–7
27 июнь, 2023 ел
РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР
Каен җиләген җыеп кал
> 3

СОЛДАТ ХАТЛАРЫ
Бөек Ватан сугышы хатирәләре
> 5



ЭШ КЕШЕСЕ
Аны күпләргә үрнәк итеп куялар
> 6

Гасыр яшьтәше

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ ЗИННӘТ ХӘЙРУЛЛИН:

«МИН ТОРМЫШТАН КАНӘГАТЬ»

Апас

Ут-сулар кичкән, гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева музеен җитәкләгән аксакал, Татарстанның атказанган укытучысы, РСФСР мәгариф отличнигы, Апас районының Шәмбалыкчы авылында яшәүче Зиннәт ага Хәйруллинга 100 яшь тулды. Бер гасырлык олы бәйрәмен каршылаган көннәрдә гомер һәм хезмәт юлын тагын бер кат искә алды ул.

18 яштә ут эченә

Зиннәт абый Хәйруллин 1941 елның 25 августында фронтка китә, беренче сугышчан чыныгуны Мәскәү янында барган сугышларда ала.

– Мин катлаулы тормыш юлы уздым. Балачагым үзгәрешләр, коллективлашу, колхозлашу чорына туры килде. Мәктәптә тырышып укыдым. Түләп уку мөмкинлеге булмау сәбәпле, техникумны тәмамламыйча, колхозга эшкә кайттым. Юл буенда арыш урган чакта атлы авылдашыбыз сугышка повестка китерде. Әни мине озатканда елый-елый кулын болгап калды, – дип искә ала Зиннәт абый.

Мәскәү, Калуга, Смоленск, Калинин, Брянск өлкәләрен, Белоруссияне, Польшаны азат итүдә катнаша ветеран. Сугышны Балтыйк диңгезе янында Кенигсберг шәһәрендә, хәрби хезмәтен 1947 елда Көнбатыш Украинада тәмамлый. Зиннәт ага – I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры.

> 2

Бәйге

Тәҗрибәле куллар

Шушы көннәрдә Дәүләт Советында Татарстанда яшәүче халыкларның мәдәни мирасын һәм үзенчәлеген саклаучы ветераннар бәйгесенә йомгак ясалды. Җиңүчеләрне парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

«Республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында мондый бәйгеләрне үткәрү аеруча әһәмиятле, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Күпмилләтле Татарстанда яшәүче халыкларның мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклауга зур игътибар бирелә. Һәр халык үз традицияләре белән горурлана. Аларның нигезенә салынган дуслык, тынычлык һәм татулык кебек кыйммәтләр республикабызны үстерергә ярдәм итә».

Дәүләт Советы Рәисе республика өлкәннәренә актив булганнары өчен аерым рәхмәт әйтте.

– Без сезнең белән горурланабыз. Сез бүген дә актив, булган хәлләргә битараф түгел, һәрвакыт вакыйгалар уртасында кайныйсыз, яшьләр белән күп аралашасыз, аларга кыйммәтле тәҗрибәгезне тапшырасыз, – диде ул.

Әлеге бәйгене Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы уздыра. Беренче этабы республика районнарында булды, май аенда җиңүчеләрне билгеләделәр.

– Әлеге бәйгенең бик кирәкле икәненә инандык. Чөнки безнең республикада талантлы кешеләр бик күп, – ди оешма рәисе Хәбир Иштирәков. – Лаеклы ялга чыккан кеше үзенә ниндидер шөгыль табарга тиеш. Ветераннарның үз талантларын күрсәтергә теләве сөендерә. Өлкәннәрнең осталыгына шаккатарлык. Күбесе – бу эшкә лаеклы ялга чыккач кына тотынган кешеләр. Югалып калмыйча, күңелен төшермичә, тормышның ямен күреп, аны башкаларга да күрсәтеп яшәүчеләргә зур рәхмәт. Алар бу эшләре аша яшь буынны да тәрбияли. Өлкәннәрдән күреп, бу эшкә оныклар да тартыла. Минә монысы – бик мөһим эш!

Узган ел халык иҗаты конкурсында 2 меңнән артык кеше катнашкан. Алар 6,5 меңгә якын эш тәкъдим иткән.

– Быел катнашучылар саны 3 меңгә җитте, 8 меңнән артык эш килде. Җиңүчеләр исемлегенә 60 кеше керде. Киләчәктә дә әлеге бәйгене дәвам итәрбез дип уйлыйм, – ди Хәбир Иштирәков.

Быелгы бәйгедә гран-при бүләгенә агачтан эшләнгән «Мәңгелек көтү» сыны өчен 92 яшьлек Илисай Имамов (Мөслим) һәм намазлык чиккән Рәмзия Фәттахова (Балык Бистәсе) лаек булды.

Чарадан фоторепортаж 7 нче биттә >

Лимон чирне оныттыра

Лимоннан әзерләнгән дарулар организмны ныгытучы, ялкынсынуларга каршы көрәшүче, микробларны юк итүче булып санала.

✓ Ул витамин җитмәгән чорда да бик файдалы. Аны яраларны дәвалаганда һәм үпкә авырулары вакытында киңәш итәләр. Шулай ук төрле агуланулар вакытында да лимон кешенең хәлен җиңеләйтә. Витамин җитмәгән чорда төнгә каршы бер лимон согы һәм 1/2 чәй кашыгы бал болгатылган 1 стакан җылы су эчеп яту да җитә.

✓ Авыз куышлыгы һәм тамактагы ялкынсынулар вакытында суга болгатылган лимон согы белән авызны чайкарга була. Ә ангина вакытында бер үк күләмдә алынган лимон согына бал кушып, тамакны чайкарга киңәш итәләр. Шулай ук һәр сәгать саен кабыксыз лимон телемен суырырга да була. Авырган вакытта көн буена кабыгы белән бөтен лимонны ашап кую да авыруның хәлен яхшырта.

✓ Астма вакытында лимон согын керән белән бергә кулланалар. 3 лимонның согын сыгып, 100 грамм угычтан уылган керән белән болгатырга һәм суыткычта сакларга. Көненә 2 мәртәбә яртышар чәй кашыгы эчәргә. «Дару» эчкәннән соң, 30 минут дәвамында ашарга яки су эчәргә киңәш ителми.

✓ Лимон белән дәваланган чорда сөт ризыкларыннан тыелып торырга кирәк. Аның составындагы эфир маен сулау кыюлыкны арттыра, кәефне күтәрә, игътибарны тупларга ярдәм итә.

✓ Лимондагы эфир мае бавыр авыруларын кисәтә. Бавыр өянәге вакытында лимон мае белән җылы компресс куярга була.

✓ Грипптан саклану өчен, лимон телемен, төкерек бүленеп чыгу туктаганчы, авызда тотарга кирәк. Элек-электән грипп эпидемиясе вакытында бөтен лимонны 1 минутка кайнар суда тотып, кабыгы белән бергә иттарткычтан үткәргәннәр. 100 г атланмай һәм 2 аш кашыгы бал белән болгатып, көненә 6–8 мәртәбә ипи телеменә ягып ашаганнар.

ИГЪТИБАР! Лимон лайлалы тышчаларны ярсыта. Шуңа да аны ашказаны, уникеилле эчәк җәрәхәте, колит, холецистит, гепатит, нефрит вакытында кулланырга киңәш ителми. Шулай ук ашказаны әчелеге югары булган гастрит һәм ашказаны асты бизе нормаль эшләмәгән очракта да лимоннан тыелып торырга кирәк.

✓ Кан тамырлары ялкынсынганда төнгә каршы юка лимон телеменнән компресс куярга киңәш ителә.

✓ Бабасырны кою өчен, 1 лимонны кабыгы, орлыгы белән бергә изеп, 1 стакан кайнар су салалар һәм 2 сәгать төнәтәләр. Тәмеңчә бал өстәп сөзәләр һәм йокларга ятар алдыннан барысын эчеп бетерәләр.

✓ Кан тамырларын чистарту һәм кан басымын нормада тоту өчен, 2шәр лимон һәм әфлисунны кабыгы белән бергә иттарткычтан үткәрергә. 2 аш кашыгы бал белән болгатып, 1 тәүлек бүлмә температурасында тотарга, аннан суыткычка куярга. Ашаганнан соң 2–3 чәй кашыгы кабарга.

✓ Йөрәк мускулларын ныгыту өчен, 250шәр грамм әстерхан чикләвеген, йөзем һәм курагәне иттарткычтан үткәрергә. Шунда ук кабыгы белән бергә иттарткычтан чыгарылган лимон, 250 грамм бал кушып, барысын бергә болгатырга. Көненә 3 мәртәбә, ашаганнан соң, 1әр аш кашыгы эчәргә.

Табигать нигъмәте

Каен җиләге

Каен җиләге яфрагы төнәтмәсендә С витамины күп. Аны кан тамырларын киңәйтү, йөрәк ритмын акрынайту өчен кулланалар. Ул шулай ук стоматит, гингивит, ангинаны дәваларга, авыздан килгән начар исне бетерергә булыша. Аның бөвел кудыргыч үзлеге дә бар.

Җиләген исә өлгергәч җыялар. Яңа сыгылган җиләк согы (көнгә 4–6 аш кашыгы) кандагы шикәрне киметә, диабеттан шифасы бар. Җиләген исә өлгергәч җыялар. Яңа сыгылган җиләк согы (көнгә 4–6 аш кашыгы) кандагы шикәрне киметә, диабеттан шифасы бар.

Халык медицинасында каен җиләген азканлылыкны, гастритны, ашказаны һәм уникелле эчәк җәрәхәтен дәвалау, үт юлындагы һәм бөердәге ташларны эретү, йөрәккә илтүче кан тамырлары атеросклерозы, югары кан басымы, остеохондроз булганда кулланалар. Ул хәл кертеп җибәрә, йончыганны бетерә.

Әмма каен җиләге кайбер кешеләрдә аллергия китереп чыгара. Шуңа да кулланганда бик сак булырга, тәнгә тимгелләр чыгып, кычыну башланугa, куллануны туктатып, кичекмәстән табибка күренергә кирәк.

Каен җиләге яфрагыннан төнәтмә әзерләү өчен:

20 г вакланган үләнгә 200 мл кайнап торган су коеп, 5–10 минут кайнаталар. 2 сәгать төнәткәч сөзәләр. Көнгә 3–4 тапкыр берәр аш кашыгы эчәләр.

ЧАЙНВОРД «САБАН ТУЕ»

Нияз Бишбалта

1. Сабан туена матур ...нәр кияләр.
2. Элек-электән бәйрәмнән бер көн алдан ... кергәннәр.
3. Язучы Г.Ибраһимов үзенең шул исемдәге хикәясендә тасвирлаган атның исеме.
4. Бәйрәмгә күп итеп тәмле милли ...лар пешерелә.
5. Сабан туенда тавык күкәе салынган ... кабып йөгергәнегез бармы?
6. ... киеп йөгерү – җиңел эш түгел.
7. ...тан тәңкә эзләргә теләсәгез, Сабан туена килегез!
8. Сабан туеның төп бәйгесе.
9. Бәйрәмдә ярышлар гадел булсын өчен, башта уенчылар ...га салалар.
10. Сабан туенда ... тартышу зур көч куюны таләп итә.
11. Сабан туе мәйданы төсле шарлар, тасмалар, милли ...лар белән бизәлгән.
12. Кешеләрнең йөзләрендә бәйрәм ...гы сизелә.
13. Казан шәһәрендә иң популяр Сабан туе була торган урын.
14. Элекке елларда Сабан туйларында ...ләр булса, хәзер аларны заманча эшләнгән җайланмалар алыштырдылар.
15. Ерактан килгән хөрмәтле кунакларны махсус корылган ...ларга утырталар.
16. Сабан туе ярышларында ... ир-атлар хөкемдарлык итә.
17. Әгәр ... битләрен актарсак, Сабан туе бәйрәменең күптәннән үк үткәрелә башлавы билгеле.
18. Ярышларны ... гадел үткәрергә тиеш.
19. Сабан туе бәйгеләрендә оту өчен, шактый ... булырга кирәк!
20. Бәйрәмне үткәрер алдыннан аксакаллар хәер-фатиха, ... бирәләр.
21. Сабан туенда күпчелек халыкның ...е бик яхшы була.
22. Сабан туе күренешләрен үзенең хезмәтләрендә чагылдырган, XIX йөздә Казанда яшәгән күренекле немец галиме.
23. Мәйданда Сабан туе символы – колгадагы чигелгән ...
24. Бу бәйрәмдә ир-атларга хатын-кызлар алдында үзләренең ...лекләрен күрсәтергә мөмкинлек күп.
25. Элегрәк Сабан туе ...сы бер генә көн түгел, берничә көн дәвам иткән.

ҖАВАПЛАР

1. Кием; 2. Мунча; 3. Алмачуар; 4. Ризык; 5. Кашык; 6. Капчык; 7. Катык; 8. Көраш; 9. Шоба; 10. Аркан; 11. Накыш; 12. Шатлык; 13. «Каенлык»; 14. Камит; 15. Трибуна; 16. Азамат; 17. Тарих; 18. Хөкемче; 19. Елгыр; 20. Ризалык; 21. Кәеф; 22. Фукс; 23. Сөлге; 24. Егет; 25. Тантана.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Фәрит ХӘМИДУЛЛИН.**

Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

«КИЛӘЧӘКТӘ ДӘ ШУЛАЙ БУЛСЫН»

Кукмара

Кече Чура авылында гомер итүче Мария Агеева, олы яшьтә булуына карамастан, язмышының барлык сәхифәләрен яхшы хәтерли. Аның 95 еллык гомер китабына бик күп истәлекләр сыйган.

Язмам герое гомере буена бер тапкыр да табибка бармаган, хәтта поликлиникада амбулатор карточкасы да юк икән. Ләкин соңгы вакытта кан басымы «уйный» башлагач, дару эчәргә туры килә икән. «Мөгаен, элек тә кан басымым булгандыр, әмма эш белән сизелмәгән. Зарланырга да күнегелмәгән», – ди ул. Кеше ярдәменнән башка кан басымын үзе үлчәргә өйрәнгән.

Мария түти йокысыннан таң белән торырга күнеккән. Аның иртәсе көндәлек эшләрдән башланып китә: яшелчә бакчасында, хуҗалыкта кайнаша, чүп утый, печән чаба... «Әни өйдә дә кул кушырып утырмый, бәйли», – дип сөйли бергә яшәүче кызы Клавдия. «Әйе, соңгы вакытта эшем бик үк килеп чыкмый, күз тидерделәр бугай, бияләйнең бармак өлешен бәйләп бетерә алмыйм, берничә тапкыр сүтәргә туры килде», – ди Мария түти.

Язмам герое 1927 елда Кече Чура авылында туа. Биредә бөтен тормышы уза.

«Йортыбыз искиткеч матур урында – су тегермәне янындагы кечкенә генә утрауда урнашкан иде. Әле дә туган нигеземне сагынам. Әни бакчада күп итеп яшелчә, җиләк-җимеш агачлары үстерде. Безнең гаиләдә 12 бала тәрбияләнде. Әтиемнең беренче хатыны алты баласын калдырып үлеп киткән. 23 яшьлек әнием аңа кияүгә чыккан. Алар алты балага гомер биргән. Бертуганнарымнан үзем генә калдым инде. Үзара тату яшәдек. Сугыш башлангач, туганнарым фронтка китте дә, өчесе шунда һәлак булды. Сарык фермасында бик иртә эшли башладым, эшем вак, катлаулы иде, каравылчы урынына да калгаладым. Аннары лаеклы ялга кадәр колхозда хезмәт куйдым. 40 елдан артык стажым бар. Эшемне намус белән башкардым, һәркем белән дус булдым, уртак тел тиз таба белдем», – дип искә ала үткәнен Мария апа.

25 яшендә ул кияүгә чыга. Ире Иван белән 5 бала тәрбияләп үстерәләр, һәрберсенә тормышта үз урынын табарга ярдәм итәләр. Бергәләп 61 ел дус-тату гомер кичерәләр. Мария түти каенана һәм каенатасы белән дә аңлашып яши.

«Без Питрау бәйрәмендә таныштык. Ул вакытта авыл яшьләре болынга уенга җыйнала иде. Дөресрәге, мин яшьләр яныннан узып киттем дә исәнләштем. Баксаң, аларның Иванны Казанга озатулары икән. Аннан кайтканда, әниемнең туганнарына еш керә идем. Бервакыт ни сәбәпледер аларда алъяпкычымны оныттым. Күрәсең, кер бавына элеп куйганмын да калдырганмын. Иван аны үзенә алган. «Алъяпкычың минем белән булыр, ә син өеңдә торырсың», – диде дә үзенең чемоданына салып куйды. Шуннан соң армиягә китте. Ике ел урынына дүрт ел хезмәт итеп кайтканнан соң, гаилә корып җибәрдек. Иван шоферлыкка укыгач, колхоз аңа яңа машина ышанып тапшырды. Шулай итеп, ул машинада әллә ничә мең чакрым юл узып, лаеклы ялга чыкты. Шул елларда авыл халкында транспорт бик юк иде. Каядыр алып барыр өчен, кешеләр аңа еш мөрәҗәгать итте. Тормыш иптәшем беркемне дә кире какмады, ярдәм кулы сузды», – дип сөйли Мария Агеева.

Кызганыч ки, Иван абый сигез ел элек бакыйлыкка күчкән. Озын гомерле Мария Агеева балаларының, 6 оныгының, 8 оныкчыгының кадер-хөрмәтендә гомер кичерә.

«Дүшәмбедән җомгага кадәр без аның белән икәү генә, ә ялларда өебездә кеше күп җыела. Киләчәктә дә шулай булсын иде», – ди кызы Клавдия.

Алсу ГАТАУЛЛИНА

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ ЗИННӘТ ХӘЙРУЛЛИН:

«МИН ТОРМЫШТАН КАНӘГАТЬ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Хезмәттә узган гомер

Зиннәт ага 1948 елдан география, астрономия фәннәрен укыта, пенсиягә чыкканчы директор урынбасары булып эшли.

– Мәктәпкә килгәч, Тәтештә педагогия училищесын тәмамладым. 1950 елда Казан педагогия институтының география факультетында укыдым. 50 ел балалар укыттым, – ди.

Лаеклы ялга чыккач та тик кенә утырырга теләми тынгысыз күңелле Зиннәт абый. Авылдашлары – атаклы опера җырчылары, Россиянең халык артистлары Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева музеен оештыруга керешә. 1993 елдан 2010 елга кадәр әлеге музей директоры булып эшли.

– Музейны оештырганда, бер экспонат та, аларны куярга өстәл дә юк иде. Үз тырышлыгым белән барын да булдырдым, – ди ул.

Зиннәт абыйның хәтеренә, камил акылына, төгәллегенә, тарихны яхшы белүенә, тормышны яратуына сокланырлык. Үткәннәр хакында озаклап сөйли ала. Аның һәр җөмләсе төзек, мәгънәле һәм тулы. Вакыйгалар, мәгълүматлар төгәл, ачык, аңлаешлы. Тормышны сөеп, яратып, һәр көненнән тәм табып яши ул. Уллары, оныклары аны кайгыртып кына тора. Кышларны Казанда уздырса да, Шәмбалыкчыда ул – үз һәм хөрмәтле кеше. Күңеле тулып ташыганда, Зиннәт абый кулына каләм ала.

– Мин тормышымнан бик канәгать. Зурлап килгән җитәкчеләргә, хезмәттәшләремә, яшь буынга зур рәхмәт. Балаларым бик тәрбияле. Оныкларым янымнан өзелми. Авыл халкы да гел хәлемне белеп тора. Матур гомер юлы уздым. Бер минутны да әрәм уздырмаска тырыштым. Хезмәтем тынгысыз булса да, нәтиҗәле булды. 100 ел 10 көн кебек кенә узган да киткән, – ди аксакал.

Котлауларда – ихлас теләкләр

Район башлыгы Айрат Җиһаншин, Бөек Ватан сугышы ветеранының өенә барып, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлауларын ирештерде, шәхсән үз исеменнән җылы теләкләрен, рәхмәт сүзләрен әйтте.

– Сезгә хезмәтегез, Бөек Ватан сугышында катнашып, илебезнең җиңүенә өлеш керткәнегез өчен бик зур рәхмәт. Сезгә карап, безнең киләсе буыннар да тәрбияләнә. Алар сезнең батырлыкка, тормыш һәм хезмәт юлыгызга сокланалар, үрнәк алалар. Исәнлек-саулык, тагын да озын гомер насыйп булсын, хөрмәтле ветеранызбыз, – диде район башлыгы.

Зиннәт аганы котларга хуҗалык һәм авыл җирлеге башлыклары, «Яшь гвардиячеләр», «Яшь армиячеләр», «Алдынгылар хәрәкәте» әгъзалары, хезмәттәшләре – район туган якны өйрәнү музее, Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева музее хезмәткәрләре, Морзалар урта мәктәбе коллективы килде. Район мәдәният йорты хезмәткәрләре Зиннәт абыйны җыр-биюләр белән сөендерде.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

Чабаксада – Мәңгелек ут

Казан шәһәренең Совет районындагы Чабакса бистәсендә Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә дан обелискы бар иде инде. Быел ул, мәгълүматларга тагын да тулыландырып, башка урынга күчерелде һәм Мәңгелек ут кабызылды. Тантанага бистәдә яшәүчеләр, сугыш ветераннарының балалары, оныклары – бик күп кеше җыелды. Чабаксадан сугышта 255 кеше катнаша, шуларның 161е батырларча һәлак була.

Совет районы хакимияте хуплавы белән обелискны төзетүдә, урнаштыруда башлап йөрүче – Татарстан агросәнәгате ветераннар советы җитәкчесе Марс Алиев.

Проектның авторлары – Бөек Ватан сугышында катнашкан Җамалетдиннең оныгы – Рөстәм Гыйльметдинов, Әнвәр Низамов, Әмир Закиров. Һәйкәл Казан шәһәренең Совет районы хакимияте һәм иганәчеләр тырышлыгы белән төзелде.

ДӨНЬЯ ӨЙРӘТӘ ИКӘН

Салагышта яшәүче II төркем группа Зөлфәт МӘҖИТОВ әнә шулай ди. Аның сул кулы хәрәкәтсез калганга инде 41 ел. Әмма авылдашларыннан калышмаска, башкалар кебек һәр көнне эшкә йөреп, маллар асрап, бакча үстереп, кешеләргә ярдәм итеп гомер кичерә ул.

Алабугадан – Уразайга

Тормыш сынаулары аны балачакта ук сагалап тора. Дүрт яшь чагында әтисе, фаҗигагә юлыгып, дөнья куя. Шөкер, әнисе Әминә апаның рух ныклыгы төшенкелеккә бирелергә юл куймый: бик актив, теләсә нинди эшне башкара алырдай егет солтаны булып үсә Зөлфәт. Мәктәпне тәмамлагач, җыр-биюне яратуы Алабугадагы культура-агарту училищесына илтә. Хореография бүлеген тәмамлаган егетне Татарстанның җыр һәм бию ансамбленә эшкә чакыралар. Әнисен ялгыз калдырып китәсе килмичә, ул туган авылы Уразайга кайта. Беренче эш урыны Рыс авылы клубы була. Язгы чәчү вакытында тракторга, урып-җыю чорында комбайнга утыра. Һәр эшне зур җаваплылык белән башкаручы Зөлфәтне Пушкин исемендәге колхозның комсомол оешмасы секретаре итеп сайлыйлар.

Бер кул белән...

Зур сынау аңа 26 яшендә килә. Мотоциклга утырган егет басу юлында һәлакәткә очрый. Борты ачылып, ашлыгы коелып кайтучы машина алдына чыгып, аны туктатырга омтылганда, каршыга килүче машинага бәрелә. Аяк, кул, кабырга, муен, борын – барысы да сына, сөякләре чәрдәкләнә. Берничә операция кичереп, хәрәкәтсез калган сул кулы, берсе җиде сантиметрга кыскарып калган аягы белән бер елдан гына сөекле җәмәгате, балалары янына кайта һәм... эшкә чыга. Башта «Сельхозхимия» оешмасында хисапчы, аннан Салагыш клубы каршындагы халык ансамблендә сәнгать җитәкчесе, бераздан ансамбль җитәкчесе була. Лаеклы ялга чыкканчы бер көн дә эштән калмаган Зөлфәтнең биографиясендә балалар бакчасында каравылда торган, бу төбәктәге эшмәкәрләрдә хезмәт иткән еллар да бар.

– Бер куллы булсам да, эш ташламадым, капчыклар да күтәрдем, кулга көрәк тә тоттым. Зарланып яшәмәдем. Мин хастаханәләрдә ятканда, җәмәгатем Лидия янымнан китмәде. Шуңа аңа ныклы терәк, ышанычлы ир булып яшәргә дигән уй белән кайттым һәм моңа кадәр сынатмадым. Бер кул белән булса да, эшләрне башкарырга өйрәтте дөнья. Җир дә казыйм, кар да көрим, маллар да карыйм әле, шөкер, – ди ул.

Гел халык арасында

Җәмәгате аның төннәр буе сызланып чыгуы, һәр көнне көчле укол һәм дарулар белән башлап, шулай ук тәмамлавы, йөрәгендә кардиостимулятор барлыгы, инфаркт кичерүе турында да сөйләде. Заманында, биеп, республика һәм бөтенсоюз бәйгеләрендә лауреат булган җәмәгатенең Уразай, Салагышта концертлар булганда сәхнәгә чыгып биер өчен ашкынып баруын һәм алкышлардан күңел күтәренкелеге алып кайтуын да яшермәде.

– Әти канаты астында үзебезне көчле хис итәбез. Ышыкланыр кыябыз ул безнең. Искиткеч кешелекле, ярдәмчел, сабыр, хөр күңелле, төпле фикерле. Күңел җылысы барыбызга да җитә. Язмыш сындырып сынаса да, төшенкелеккә бирелгән чагын күрмәдек, сизмәдек. Ул – гел кешеләр арасында. Шундый әтиебез белән горурланып яшибез, – ди балалары.

...Салагыш авылында һәр көнне, өйлә намазы җиткәнне белдереп, моңлы азан тавышы яңгырый. Зөлфәт авылдашларын дин юлына өнди шулай. Туган авылы Уразайда, гомер иткән Салагышында бакыйлыкка күчкәннәрне соңгы юлга озатырга да бармыйча калмый. Әнә шулай башкаларга кулдан килгәнчә ярдәм итүдән ямь табып яши Зөлфәт кардәшебез.

ӘНКӘЙНЕҢ ДОГАЛАРЫ

Хатын-кызның бөтен асыл сыйфатларын үзенә туплаган гүзәл ханым, диләр аның хакында. Кырынды авылында яшәүче дин кардәшебез Салисә Тимершина Коръәнне алты тапкыр укып чыккан.

Әнисе һәм әбисе тәрбиясендә

Салисәнең Хәбибә әбисе бик укымышлы була. Авылдашлары аңа дини сораулар буенча да, өшкертергә дип тә еш мөрәҗәгать итәләр.

– Балачакта әбием белән сәхәргә дә тордым, ураза да тоттым, догалар да өйрәндем, – дип зур хөрмәт белән искә ала ул күңеленә иман орлыкларын салган әбисен.

Әнисе Әминә дә бик күп догалар белгән.

– Мин мәчеткә сәдака китергәндә: «Балам, син аны әниеңә бир, ул аңа тиешле», – дип кабатлыйлар иде мәчет картлары, – ди Салисә апа.

Мөгаллимәләргә рәхмәт

Мәктәпне тәмамлагач, башка яшьтәшләре кебек, Ижауга китә Салисә. Заводларда эшләгәндә күп тапкырлар төрле бүләкләргә лаек була. Төнге сменада эшләгәндә буш вакытта догалар ятлый. Лаеклы ялга чыккач, җәмәгате Сәлимулла белән туган авылы Кырындыга кайтып төпләнәләр.

Кайту белән Кырынды мәчетенә йөри башлый.

– Мөгаллимә Рәисә Кәримуллина һәм Мәгъфия Хаҗиева мәктәп балаларына гарәп хәрефләре өйрәтә иде. Мин дә аларга кушылдым. Намазга баскан идем инде. Чаллыдан килеп дини гыйлем өйрәтүче мөгаллимә Зөһрә Зариповадан да күп нәрсәгә өйрәндем. Моннан биш ел элек Әгерҗедә район күләмендә уздырылган Коръән укучылар бәйгесендә өченче урын алуыма Кырынды мәчетенә йөрүче дин кардәшләрем миннән дә ныграк сөенделәр, – ди Салисә апа, мөгаллимәләрнең һәммәсенә дә рәхмәтле булып. – Мәчетебезнең гөрләп эшләвенә сөенәм. Дин кардәшләребезне җыеп, ифтар ашлары, Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре уздыру өчен бөтен шартлар да булдырылды. Без, хатын-кызлар, һәр пәнҗешәмбедә Аллаһ йортына җыелабыз. Ул көнне бәйрәм кебек көтеп торабыз. Дингә керүчеләр саны арта. Кырынды мәхәлләсендә 13 хаҗи бар хәзер. Без дә җәмәгатем Сәлимулла белән 2014 елда хаҗ сәфәре кылдык.

Йөрәге тулы мәрхәмәт

Мәчеттә уку елы башлангач, ике ел шөгыльләнгән төркемгә яңа өйрәнергә теләүчеләр дә кушыла. Шул чакта мөгаллимәләр Рәисә Кәримуллина һәм Мәгъфия Хаҗиева Салисә Тимершинага яңа укучыларга белем бирергә тәкъдим итә. Ул, җиң сызганып, эшкә керешә. Тырышлык бушка китми: яңа укучылар алдан өйрәнә башлаганнарны бер ел эчендә куып җитәләр. Әнә шулай мөгаллимәлек эшен дә уңышлы башкара дин кардәшебез.

– Салисә – хатын-кызның бөтен асыл сыйфатларын үзенә туплаган гүзәл ханым. Аш-су остасы буларак, мәчеттә уздырылучы мәҗлесләргә әзерләнергә беренчеләрдән булып килеп җитә. Йөрәге тулы мәрхәмәт, һәркемгә дә күңел җылысы мулдан аның, – диләр авылдашлары.

– Әниебез Әминә әбиебез кебек изге күңелле булып яшәргә омтылса, без исә аның үзе кебек зирәк акыллы, бай рухлы булырга тырышабыз. Әни догасыннан, күңел җылысыннан аермасын безне Ходай! – дип телиләр балалары.

Асия КОРБАНГАЛИЕВА әзерләде

«ШУЛАРНЫ УКЫП, МИНЕ ИСКӘ АЛЫРСЫЗ»

*«Татарстан ветераны» кушымтасында Бөек Ватан сугышында катнашкан солдатларның хатларын тәкъдим итәбез. Әлеге истәлекләрне редакциягә КФУ профессоры **Марсель БАКИРОВ** тапшырды.*

ЗАРИФ НАСЫЙБУЛЛИН

Ул сугышка Лаеш районыннан китә.

Икенче хаты. 31 август, 1941 ел.

«Хәзергә үзебезнең хәл шундый: августның 12сендә, машиналардан төшеп, Смоленск шәһәренә якынайдык. Мәскәүгә кадәр тыныч иде, Мәскәүдән соң шактый юл үткәч, тынычсызга китә башлады. Ерактан ук гөрселдәгән тавышлар котны алып тора, фашист самолетлары һаман бомба ташлап тора, безнең өскә дә менә-менә килеп ташлый, дип бардык. Барып җитәрәк өч самолет килеп чыгып, бомбага тоттылар, ләкин безнең эшелонга эләкмәде. Бомбалар ташлаганда, вагоннардан чыгып, читкә таралдык. Безнекеләр ул самолетларга зениткалардан аттылар.

Без килеп урнашкан җирдән сугыш ерак түгел инде, туп тавышлары бик ачык ишетелә. Үзебез хәзер урман эчендә ятабыз. Озакламый без дә алгы сызыкка ук китәрбездер, ахыры хәерле булсын.

Ашарга-эчәргә бар әле. Мәскәүдән булкалар алган идек. 1 сум 80 тиенлек булкалар, ашап бетергесез. Юлда барганда мин инде сезгә бер хат язып салдым. Бусы – 2 нчесе. Моннан соң хат салырга да вакыт булмас инде. Сугыш барган җиргә бик якын торабыз, Аллага тапшырдык. Озакламыйбыз, без дә ут эченә керербез. Ашыгыч арада гына язып алдым. Ярый, хуш. Зинһар, Җәмилә, балаларны сакла, аларны рәнҗетә күрмә. Ирләр башкарасы күп эш Госман өстенә төшә инде.

Безнең өчен кайгырмагыз, ил өстенә килгән афәткә каршы без көрәшмичә, кем көрәшсен? Илне, сезне саклау безнең төп бурычыбыз инде.

Өченче хаты. 9 сентябрь, 1941 ел.

«Үзебез Смоленск урманында сугышка кирәргә команда көтеп торабыз. Сугыш бездән 30–35 чакрымнар ары, атыш тавышлары ишетелеп тора. Без торган урман эчендә бары да киеренке хәлдә. Дошман самолетлары безнең өстән әледән-әле әйләнеп китәләр. Самолетлар ялгыз гына түгел, 5әрләп, 10арлап оча, һаман бомбага тотып торалар.

Лагерьдан чыкканнан бирле аяк киемнәрен салган юк, ашау-эчү дә бертөрле генә, үзегез чамалыйсыздыр инде. Моннан соң тиз генә хат язулар булмастыр сыман. Бу хатны да каравылдан алышынгач кына язып алдым. Буш ара юк, хәрби өйрәнүләр күп вакытны ала. Бу – минем өченче хатым. Якташлар хәзергә бишебез дә бергә. Авылларыбыз һәм якыннарыбыз турында сөйләшеп алабыз. Сафин Гәрәй дә минем янда. Адреслы хат килсә, һәрберебезгә дә шул адрес ярый.

Сез бик борчылмагыз. Дошман безнең якларга барып җитә алмас, без илебезнең ул кадәр үк эченә үтәргә ирек бирмәбез. Безнең турыда да бик кайгырмагыз. Булган агачларны саклап ятмагыз, ягыгыз. Исән-сау дошманны җиңеп кайтсак, барысы да булыр. Бу хатны алу белән үк авыл хәлләрен язып сал, Җәмилә. Хәзер сентябрь, көннәр суыкка бара, бәрәңгеләреңне йолкып-йолкып булса да ала торыгыз. Бәрәңге – «икенче икмәк» ул».

Дүртенче хаты. 18 сентябрь, 1941 ел.

«Үзем хәзергә сау-сәламәт, сезләрне дә сәламәт булсын дип теләп калам. Без хәзер алгы сызыктан 20 чакрым чамасы ераклыкта гына. Без дошман янына ук барып җиткән идек инде. Алгы сызыкка 3 чакрым калгач, кире чигендерделәр. Кырда траншея һәм окоплар казыйбыз. Бу хатны да окоп казыган арада гына язып салдым. Көн саен, сәгать саен дошман белән йөзгә-йөз очрашуны көтеп торабыз. Әллә бүген, әллә иртәгә таңда ук алгы сызыкка чыгарырлар. Аллага тапшырдык, хәерле булсын.

Монда гыйбрәтләр, афәтләр күп: тирә-якта авыллар яна, миналар шартлаганы ишетелә, баш очыннан гына вакыт-вакыт дошман самолетлары очып үтә. Сугыш хәлен үзегез чамалыйсыздыр. Үзебез хәзергә бишебез дә бергә: Хәмәтгали, Закир, Зиннәт, Гәрәй һәм мин.

Башкаларыбыз арттa калды. Монда көннәр начар, яңгырлы. Бер яктан дошман самолетлары бомбалар ташлап китә, икенчедән, өс-баш манма юеш. Бу – минем дүртенче хатым. Соңгысы булмаса ярый инде. Ул-бу булса, бәхил булыгыз. Йорт-җирен саклау өчен, безнең өчен башын салды дип искә алырсыз».

Ә менә түбәндәге хат Зарифның авылдашы Гәрәй Сафинныкы. Ул авыл хуҗалыгын күмәкләштерү чорында беренчеләрдән булып колхозга кергән һәм Хәерби авылында оешкан әлеге колхозның ун ел буена иң беренче рәисе булган. Сугышка Зариф Насыйбуллин белән бергә алынган һәм аның белән бер үк ротага эләккән, иң аянычлысы, аларның үлемнәре дә Смоленск тирәсендә бергәләп катнашкан бер үк сугышка туры килгән. Әмма хатта үлем турында бер сүз дә юк, киресенчә, хат авторының яшәргә ашкынуы сизелеп тора. Шул ук вакытта аерым юллардан баштагы чорда безнекеләрнең бик авыр хәлдә калганлыкларын, үзара бәйләнешләрнең өзелгәнлеген дә чамаларга була.

12 сентябрь, 1942 ел.

«Безнең хәлне сорасагыз, без хәзергә сау-сәламәт, сезләрне дә сау-сәламәт дип беләбез. Мин хәзер пулеметчылар командасында, пулеметтан атарга өйрәндем. Хәзер хәрби өйрәнүләрне бетердек. Якташ һәм авылдашлардан Хәмәтгали, Зариф, Закир, Зиннәт – дүртесе дә безнең ротада. Көне-төне бер тирәдә кайнашабыз, сугышка керергә әзерләнәбез.

Көзге уңышны, бәрәңгеләрне яхшы гына итеп җыярга карагыз, киләчәктә ашарга кирәк булыр. Исән-сау кайтсак, безгә дә кирәк булыр. Авыл җирендә шундый сөйләүләр була: Герман килә, фәлән дә төгән, дип. Бер дә куркырга ярамый. Тагын әллә никадәр вакыт сугыш булса да, Герман анда барып җитәчәк түгел. Колхозда армый-талмый эшләргә карагыз, без дә монда тырышачакбыз. Зарифтан Җәмиләгә һәм барча балаларына сәлам. Без монда, Смоленск урманнарына килгәннән бирле һаман агач төбендә кунабыз. Фронтка якын торсак та, сугышларның ничек баруы безгә билгеле түгел. Кайсы кеше, Смоленск безнекеләр кулында, ди, кайсы, немецлар алган, ди. Дөрес итеп әйтүче юк. Газеталар алганыбыз юк. Сау булыгыз. Исәнлектә кайтып күрешүне теләп калам. Шуңа өметләнеп, сәлам белән Гәрәй».

ДӘҮЛӘТША ХӨСНУЛЛИН

Элекке Кызыл Йолдыз (хәзерге Балык Бистәсе) районының Котлы Бөкәш авылында почта начальнигы булып эшләгән Дәүләтша Хөснуллин, сугыш башланып киткәндә, Иваново шәһәрендә кече командирлар әзерләү курсында була. Ул сугышка шуннан китә һәм Мәскәү өчен барган сугышларда яраланып, Владимир шәһәрендәге госпитальдән хатыны Хәтимәгә һәм кызы Розагa өч хат сала. Госпитальдән чыккач, кабат фронтка җибәрелә.

22 июнь, 1941 ел.

«Җаным! Иртәнге 4 сәгатьтә Германия безгә каршы сугыш игълан итте. Бу зур сугыш булачак. Аннан без читтә кала алмыйбыз инде. Безгә юлга әзерләнергә куштылар. Курсантлар хәзер мәш килә: кайсы посылка ясый – артык әйберләрен җибәрергә, кайсы хат яза. Минем җибәрер әйберем юк. Сиңа һәм кызыма шушы хат аша сагынычлы сәламнәремне генә җибәрәм. Үзегезне саклагыз. Минем өчен кайгырма. Исән булсак, беркайчан да югалмабыз.

Кулыңны кысып калучы Дәүләтша».

27 гыйнвар, 1942 ел.

«Җаным, исән генә торасызмы? Сөекле кызым Роза үсәме? Белмим, утынга интегә торгансыздыр инде сез. Ягарыгызга юнәтүе авырдыр. Быел кыш бик салкын бит. Карт кәҗәбез турында сорамыйм да инде. Ул ачтан яки тәрбия җитмәүдән егылып үлгәндер.

Мин хәзер савыгып беттем дияргә дә була. Берничә көннән комиссия үтәм дә тагын фронтка, сугышка китәчәкмен. Минем шуны беләсем килә: син военкоматтан акча аласыңмы, юкмы? Мин үземнең исемгә лейтенант буларак ай саен 400 йөз сум күләмендә бирелә торган акчаны сезнең адреска салып торуларын сорадым. Минем өчен бер дә кайгырма, исән булсак, күрешербез».

ГАБДЕЛХАК ШАГИН

Ул да чыгышы белән шул ук Кызыл Йолдыз (хәзерге Балык Бистәсе) районының Котлы Бөкәш авылыннан була. Унынчы сыйныфны тәмамлагач, ул үз теләге белән сугышка китә һәм Псков өлкәсенең Великие Луки шәһәре янында барган каты сугышларда авыр яралана. Ул хезмәт иткән взвод командиры, Мөслим районының Мәлләтамак авылы кешесе лейтенант Зиннур Әхмәтовның фронттан Котлы Бөкәшкә килгән хатына караганда, яралы Габделхакны ике солдат тылга чыгарырга алынган була. Юлга кузгалганда гына өсләренә мина төшеп ярыла һәм болар өчесе дә иптәшләре күз алдында һәлак булалар. Шундый аянычлы язмышка дучар булган егетнең сугышка чыгып китәр алдыннан язган хатында якыннарына адресланган җылы хисләре һәм рәхмәт сүзләре, шулай ук яшәүгә өметләнүе, хыяллары теркәлеп калган.

4 сентябрь,1942 ел.

«Без Иваново шәһәреннән 10 августта китеп, Мәскәүдән 150 чакрым ары барып урнашкан идек. Шушы көнгә кадәр шунда тордык. Районнан берүзем генә. Хәер-догагыздан ташламагыз. Кайта алмасам, бәхил булыгыз. Дәү абыстай, кечти апа, әти, әни, шушы яшемә кадәр карадыгыз, өрмәгән җиргә дә утыртмый тәрбияләп үстердегез. Монысы өчен бик рәхмәт. Тик шушы яшемә җитеп, үземнең генә бер ярдәмем дә тимәде. Әгәр исән булып, әйләнеп кайта алсам, картлык көнегездә боларны кайтарырмын. Улыгыз Габделхак».

ҮЗЛӘРЕ КОРГАН БӘХЕТ

Чүпрәле

Аларның туй, никах көннәре бүгенге яшьләрнеке кебек купшы узмаган, кәләш белән кияүнең кияр киемнәре дә әллә ни затлы булмаган, кунакларны да өйдә ни бар – шуның белән генә сыйлаганнар. Ярый ла бер-берсен күрешеп, белешеп кавышсалар. Күп вакыт димләп, яучы җибәреп гаилә корганнар. Шуңа да карамастан, дистә еллар гаилә ныклыгын, бер-берләренә булган ихтирамны саклап кала алганнар. Әлеге язма – Чүпрәле районының күркәм гаиләләре турында.

Тимер туй

Мөнирә һәм Тимерша Гыйззәтуллиннар инде 65 ел бергә. Биш бала тәрбияләп үстергәннәр, җиде оныклары һәм биш оныкчыклары бар.

Алар – районның иң өлкән пары. Март аенда Тимерша абый 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

–1958 елның 1 февралендә Зур Чынлы авылыннан шушы нигезгә килеп кердем. Мине монда күрше апалар димләп бирде. Башыңны бер бәйләгәч, кайтып китү юк инде. Өйдә дә бу турыда: «Барган урыныңда таш бул», – дип бер генә әйтелгән. Каенатам сугышка китеп, шунда ятып кала. Каенанам өч баланы ирсез, ялгызы үстерә, эшкә өйрәтә. Бик акыллы карчык иде. Әле яннарында укытучы бер бабай яши иде, – дип сөйли Мөнирә апа. – Ходайга шөкер, яхшы тордык, каенанам балаларны үстереште, эштән пешкәнгә кайттык, ишекне бикләп йөрмәдек, 35 ел бергә гомер иттек аның белән.

Гаиләне хатын-кыз саклый. Мөнирә апа шулай ди. «Артыгын сөйләмәскә, кирәк урында борылып торырга кирәк. Кара-каршы әйткәләшсәң, бер-береңә юл куймасаң, көн юк инде. Һәр кешенең бәхете – үз кулында, шуны онытмаска кирәк!» – ди ул. Белеп әйтә.

Гомерләре буе колхозда эшли алар. Тимерша абый лаеклы ялга чыккач та, участок хастаханәсенең атларын карый әле. Мөнирә апа исә колхоз бакчасында яшелчәләр үстерүдә озак еллар хезмәт куя. II дәрәҗә «Ана даны» медале иясе ул. Бүген икәү генә гомер итсәләр дә, бала-оныклар әзне суытмый төп йорттан.

Бриллиант туй

Сабырлыкны, тормышны яратуны бәхетнең нигезе, дип саныйлар Зур Чынлы авылында гомер кичерүче Мөслимә һәм Мидхәт Юсуповлар.

Алар бер урамда үсә. Яшьли бер-берсен ошатып йөриләр һәм 1963 елның апрелендә кавышып та куялар. «Элек бит мәзәк утырыш бар иде, яшьләр шунда җыела, очраша идек. Ак күлмәкләр кия алмадым. Ул елларда ситсы, штапель материалдан тектерә алсаң да зур бәхет. Шулай да туйлар матур узды, берничә көн кунак йөрешеп, аннан «арчи» – яшьләр йөреше дә бар иде. Һәр чорның – үз матурлыгы, үз истәлеге. Безнең дә сагынып сөйләрлек хатирәләр бар», – дип искә ала Мөслимә апа.

Икесе дә күпбалалы гаиләдә туа алар. Мидхәт абый – җиде баланың төпчеге. Яхшы тормыш эзләп, гаиләләре белән Баку якларына төянеп чыгып китәләр. Әмма сугыш башлана. Әтисе, ике олы абыйсы яу кырына китә. Әниләре исә калган балалары белән янә авылга кайта. Бу вакытта Мидхәт абыйга 3 ай гына була әле. Әтиләре һәм бер абыйлары сугыштан исән-сау кайтмый.

Мөслимә апа исә биш баланың олысы булып үсә. Әтисе сугыштан яраланып кайта. Авырлыкларны күп күрәләр, әмма сынмыйлар, сыгылмыйлар. Бар гомерләре хезмәттә уза. Мидхәт Кәлимулла улы авылда пилорама ачылганның беренче көннәрендә андагы бар җиһазны урнаштырып, көйләп җибәрә.

Бүген алар төп нигездә икәү яшиләр, авылда кызлары төпләнеп калган, калган балалары – Ульяндә. Тормыш иткәндә тәрлесе була: сикәлтәсе дә, авырлыгы да. Юсуповлар олы кызларын югалту кайгысын да кичерәләр. Барысын уртак итеп яшәү бәрабәренә бүгенге бәхетле картлык көннәрен бергәләшеп уздыралар.

Тормыш булгач, була төрлесе

Сәкинә һәм Рөстәм Хәсәновларның яшьлеге дә, бүгенгесе дә гүзәл туган яклары Яңа Дуван авылында уза. 2023 ел алар өчен дә истәлекле, 60 ел бергә гомер итүләрен, бриллиант туйларын бәйрәм итәләр.

Авыл тормышы бервакытта да җиңел булмаган, ләкин алар беркайчан да зарлануны белми, һәр эштән тәм табып, тормышның кадерен белеп яши.

Сугыштан соңгы елларда эшне иратныкына һәм хатын-кызныкына бүлү булмый. Урман кисүдә дә, печән чабуда да гел бергә булалар. Бүрәнәнең авырын да, җиңелен дә бергә күтәргән кебек, тормыш йөген дә Хәсәновлар икәүләп тарталар.

Рөстәм абыйның гомере колхозда механизатор хезмәтендә уза. Язын, көзен җир сукалауда, чәчүдә, уңыш җыюда эшли. Сәкинә апа исә – сыер савучы. Икесе дә намуслы хезмәтләре өчен мактала, хезмәт ветераннары.

60 ел буена шатлыклары да, кайгылары да уртак булган аларның. Тату гаиләнең мәхәббәт җимешләре – биш бала дөньяга килгән. Нәсел дәвамчылары булып, җиде онык, ике оныкчык үсеп килә.

Язмышларында булган барлык авырлыкларны икәүләп җиңеп үткәрә алар хәзер дә. Һәр көннәрен Ходайга тапшырып, үзләре белән бер нигездә гомер итүче уллары, киленнәре өчен өлкәннәр төп таяныч, ярдәмчеләр булып яшиләр.

Гөлия ФӘИЗОВА әзерләде

ТАТАРСТАНДА ЯШӘҮЧЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫН ҺӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН САКЛАУЧЫ ВЕТЕРАННАР БӘЙГЕСЕННӘН

ФОТОРЕПОРТАЖ



Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Шигърият

Исхак ФӘЙЗИ

* * *

Әле генә шатланышкан идек,
Яз килде, дип, туган якларга.
Бөре исен иснәп туймасак та,
Вакыт җитте җәйгә атларга.

Алмагачлар инде чәчәк коя,
Тузганаклар мамык тарата.
Төннәр кыска. Кичке шәфәкъ сүнгәч,
Көнчыгыштан яңа таң ата.

Кояш ерак, ләкин туры карый,
Шатландырып болын гөлләрен.
Кем яратмый гүзәл табигатьнең
Яздан җәйгә күчкән мәлләрен?!

Тугайларда җылы җилләр исә,
Сусыл үләннәрне игәләп.
Көн кызуын сүрелдереп кенә
Яңгырлары китә сибәләп.

Башка төсләр эреп юкка чыкты,
Хөкем итә җирдә яшеллек.
Май узса да, һаман түгел әле
«Яз үтте» дип сыкрап дәшәрлек.

Иң матур чак! Эшләр бик күп түгел,
Чәчү белән урак арасы.
Авылларда бергә җыелышып,
Сабантуйлар ясап каласы.

Кайтасы да килми болыннардан,
Әсир итә сихри хозурлык.
Саф һавадан, яшел табигатьтән
Көч-дәрт алып калыйк бер еллык.

* * *

Гомер ага елгадай,
Бүген мин булдым бабай.
Ләкин, картаям икән дип,
Саргаеп тормыйм алай.

Кызык инде бу адәм!
Яшь барса да, яшәрәм.
Дәвамчыларым булганда,
Гомерем үтмәс әрәм.

Туа торсын оныклар,
Тынычланып холыклар,
Яшик әле карчык белән
Әби-бабай булыплар.

Балаларга булышып,
Сабыйларын багышып,
Тормышларны ямьләндерик,
Җан җылыбызны кушып.

Ә гомер барса барсын,
Гел санап тормыйк анысын.
Оныклар аша тарихта
Якты эзебез калсын.

* * *

Яшь чагында акыл җитми,
Олыгайгач – юләрлек.
Алдын-артын күп уйлыйбыз,
Көч булса да юнәрлек.

Яшь чагында яр сайлыйбыз,
Эш сайлыйбыз гомерлек.
Соңыннан, тапсак та, булмый
Күңелгә хуш килерлек.

Яшьли дуслар күп табыла,
Олыгайгач – бик сирәк.
Башкаларны ишетмибез,
Үз сүзебез көчлерәк.

Яшь чагында вакыт җитми,
Картайгач – сәламәтлек.
Табиблар да синең хәлне
Аңламый үзең хәтлек.

Яшь кешегә шаукым кирәк,
Өлкәнгә – тыныч тормыш.
Дусларым, уйлап карагыз:
Хакмы бу чагыштырмыш?

ЭШЛИ ДӘ, ЭШЛӘТӘ ДӘ

Азнакай

Районның ветераннар советы – Татарстанда иң өлкәне: 1972 елда төзелгән бу оешма былтыр үзенең 50 еллыгын билгеләп үтте. Яше белән генә түгел, эшләре белән дә данлы ул. Республика ветераннар советы президиумының берничә ел элек безнең район җирлегендә үткәрелгән күчмә утырышында Татарстан иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәковның: «Азнакай тәҗрибәсе – һәр оешмага өлге», – дигән сүзе дә раслый моны.

Менә 18 ел инде районның ветераннар советы белән Азнакайның мактаулы гражданины, «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» ордены медале иясе Миргасим Кәримов җитәкчелек итә. Аның энергиясенә, оештыру сәләтенә хәйран калырлык. Үзе дә тик тормый, безне дә эшсез тотмый. Ничек шулкадәр идеяләр туып кына торадыр башында…

Нәкъ менә аның тәкъдиме белән Мәңгелек ут янында тыл ветераннарына һәм сугыш чоры балаларына һәйкәлләр куелды; районның үсешенә зур өлеш керткән, югары дәүләт бүләкләре алган, атказанган хезмәткәр исеменә лаек булган кешеләрнең исемлеген булдырып, аларны хөрмәтләү тантанасы оештырылды; 20шәр, 30ар ел колхоз-совхозларга, урта мәктәпләргә, предприятиеләргә җитәкчелек иткән күренекле шәхесләргә истәлек такталары куюо кертелде. Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган республика конкурсының өч этабында да Азнакай ветераннар советы алдынгылыкны бирмәде.

Билгеле булганча, кешенең холкын, эшкә сәләтен кайда, нинди шартларда үсүе билгели. Миргасим Ильяс улы районыбызның Мишәр Мөслиме дип йөртелә торган авылында 1943 елның 12 июнендә ишле гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Әнисе, чибәрлеге белән дан тоткан Салиха апа, балаларын, ирен, хуҗалыгын кайгыртып-карап яши. Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайткан Ильяс абый исә 15 еллап колхоз рәисе, соңрак ферма мөдире булып эшли. Терлекчелектә югары күрсәткечләргә ирешкән өчен илнең иң югары бүләге – Ленин ордены белән бүләкләнә. Гаиләдәге дүрт малай да кыю, нык булып үсәләр, әтиләре кебек көрәш белән шөгыльләнәләр, гер күтәрәләр. Сабан туйларында батыр калалар.

Миргасим да мал карап, кыр эшләрендә катнашып, көрәшләрдә ныгып үсә. Германиядә 3 ел танк гаскәрләрендә хезмәт итеп кайткач, Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына укырга керә. Студентларның төзелеш отряды командиры булып, ике ел Казахстанда эшли. Ике елда да Миргасим җитәкләгән отряд Татарстанның 14 югары уку йорты арасында беренче урынны яулый!

Хезмәт юлын Миргасим Кәримов үзебезнең төбәктәге Мәлбагыш авылында агроном буларак башлап җибәрә. Авыл хуҗалыгы министрлыгында һәм партиянең район комитетында эшли, сигез ел дәвамында районның баш агрономы була. Зәй һәм Азнакай районнарында авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы булып эшләү чорында Саратовта югары партия мәктәбен тәмамлый. Шактый вакыт хакимият башлыгы урынбасары һәм контроль комитеты рәисе булып эшләп, лаеклы ялга чыга. Аның хезмәте күп мактау кәгазьләре, «Чирәм җирләрне үзләштерү өчен», «Фидакяр хезмәт өчен» медальләре, ВДНХның көмеш медале, «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме белән бәяләнә. Карабодай игүдә югары казанышлары өчен 1986 елда ул СССР Дәүләт премиясенә лаек була.

Гомер буе командирлык сыйфатын югалтмыйча яшәүче мәһабәт гәүдәле, көр тавышлы, бетмәс-төкәнмәс энергияле Миргасим Кәримов 2005 елдан бирле район һәм шәһәр ветераннар советын җитәкли. Чын лидер ул. Аның инициативасы белән ел да көзнең матур бер көнендә «Әбиләр чуагы» бәйрәме оештырыла. Бөтен авыллардан, хәтта күрше районнардан һәм Башкортстаннан киләләр бу бәйрәмгә. Пневматик мылтыктан ату буенча «Ворошилов укчысы» бәйгесе, шашка, шахмат, бильярд, йөзү ярышлары, җәйге Сабан туе традициягә керде. Төрле экскурсияләр, очрашулар, ял кичәләре, «Суперәби», «Супербабай» конкурслары күңелләрдә онытылмаслык хатирәләр калдырды.

Мәктәпләрдә укучылар белән очрашулар оештыру, районның һәр авылында, һәр хезмәт коллективында, тарихын, күренекле кешеләрен барлап, бай эчтәлекле альбомнар төзү, күрше авылларның бу альбомнары бәйрәм шартларында бер-берсенә эстафета итеп тапшыруы… Күпме көч, вакыт, фикер, тәвәккәллек, оештыру сәләте кирәк болар өчен!

Кабинетта команда биреп кенә утырмый, үзе дә җигелеп тарта ул. 80 яшен билгеләп үткән бу көннәрдә дә иртәнге 4тә торып, армиягә китүче егетләрне озатырга бара, үзе хәрби хезмәт үткән, капитан дәрәҗәсе алган кеше буларак, аталарча киңәшләрен бирә. Аксакал игенчеләр белән басу-кырларның торышын карап кайта. Сугыш ветераннарын, зурлап, соңгы юлга озата. Картларның хәлләрен, сәламәтлеген белешеп тора, туган көннәре белән котларга да онытмый!

Район ветераннар советы урнашкан бинада иртәнге якта халык та өзелми, телефон да тынмый. Өлкән яшьтәгеләр кайсы – ярдәм, кайсы киңәш сорап килә, кайсы эчен бушатырга керә. Ни кызганыч, балаларыннан, оныкларыннан зарланучылар аз түгел бу заманда. Кәримов һәркемгә ярдәм итәргә тырыша. Район башлыгы Марсель Шәйдуллин да еш килә безнең янга. Ветераннар советының бөтен эшендә терәк булып тора.

Җәмәгать оешмасында эшлим дигән кешегә эш җитәрлек. Күргәзмәләрдә, конкурсларда катнашабыз, стендлар, тематик альбомнар төзибез, өмәләр ясыйбыз, бакчада гөлләр, яшелчәләр үстерәбез. Көз көне шушы бакча нигъмәтләрен Актүбәдәге картлар йортына илтәбез. Пенсионерлар өчен ачылган Аралашу үзәге, шахмат, бильярд клублары, җыр һәм бию ансамбльләре эшләп тора. Быел шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары арасында үткәрелгән үзешчән сәнгать смотр-конкурсында безнең ветераннар коллективы мактаулы икенче урынны яулады, «Балкыш» фестивалендә биш номерыбыз Казандагы гала-концертка үтте. Шәһәрнең күркенә әйләнгән Кара елга буйларын төзекләндерүгә дә өлешебезне керттек дип горурланабыз.

Ветераннар советының актив, инициативалы эшләвен Казанда да, районда да сизеп-күреп торалар. Җитәкчебез Миргасим Кәримовның абруе зур. 2021 елда ул «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз күзлегеннән» дигән республика конкурсында җиңде. Татарстан Президентының һәм Дәүләт Советының Рәхмәт хатларына, «Татарстан Республикасында ветераннар хәрәкәтен үстерүдә хезмәтләре өчен» Мактаулы билгесенә, «Россия Федерациясендә ветераннар хәрәкәтен үстерүдә хезмәтләре өчен» Мактау билгесенә лаек булды. Ветераннарның Мәскәүдә үткәрелә торган Бөтенроссия съездлары делегатлары арасында безнең Миргасим Кәримов та булды. Эшенә, тырышлыгына зур бәя бу.

Нәсимә КАМАЛИЕВА

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Оста кул

Арча

Атлас Солтанов күптәннән лаеклы ялда. Әмма бер минут тик тормый. Без аның белән Арчаның Ямашев урамындагы остаханәсендә очраштык.

Ишегалдына керүгә кәкре-бөкре агачларга игътибар иттем. «Минем эш материалларым шулар инде, – диде каршы алырга чыккан хуҗа. – Мин шундый кәкре-бөкре тамырлар, агачлардан сыннар ясыйм, ягъни табигать тудырган әйберләрне үземчә эшкәртәм. Корнепластика дип атала ул. Яңа Кырлайдагы сыннарга игътибар иткәнегез бардыр. Бакый Урманче да аларны нәкъ менә сәнгатьнең шул төрен кулланып ясаган», – дип сөйли оста.

Атлас Солтанов Азнакай районының Чалпы авылыннан. Гаиләдә сигез бала үскәннәр. Шуларның бишесе – малай. Әтиләре – балта остасы. Менә кайдан килгән аңа агач эшенә мәхәббәт.

– Әтигә ярдәм итеп үстек. Рубанокларны дүрт кул белән тарта идек. Ике якта ике кеше. Берсе әти булса, берсе – без. Мәктәптә Әмирҗан абыйның хезмәт дәресләрендә дүрт аяклы артсыз урындыклар, балта, чүкеч, чалгы саплары ясарга өйрәндек. Аннан мин Лениногорскидагы педагогик сәнгать-музыка училищесына укырга кердем. Рәсем бүлегендә белем алдым. Бер елдан укуны өзеп, армиягә киттем. Германиядә хезмәт иттем. Анда да рәсем ясадым. Сәләтемне бик тиз белеп алдылар. Шунда ату спортына кереп киттем. Оста спортчылар рәтендә йөрдем. 1992 елга кадәр ату буенча республика ярышларына йөрдем, призлы урыннар яуладым. «Социалистик Татарстан» оештыра иде аларны. Арча районына килгәч тә бу шөгылемне дәвам иттем. Район җыелма командасы составында беренчелекне бирмәдем, команда да биш ел рәттән чемпион исемен яулады, – ди ул.

Ә Арча якларына ничек килеп чыккан соң Азнакай егете? Армиядән соң ул училищеда укуын дәвам итә. Аннан юллама буенча педагогика көллиятенә эшкә килә. Үзе генә түгел, шулай ук әлеге училищены тәмамлаган хатыны Лидия Александровна белән. Икесе дә гомер буе көллияттә эшли.

Лидия һәм Атлас Солтановларның ике кызлары бар. Берсе – Божада, икенчесе Казанда яши. Божадагы кызлары оста дизайнер, интерьер, күргәзмә проектлары эшли. Икенче кызларына да әти-әнисенең сәләте йоккан, ул төрле материаллардан өй өчен кирәк-яраклар ясый.

Кул эшләрен сата да ул, бүләк тә итә. Туганнарга, дусларга. Ул ясаган сыннар арасында гөл чүлмәге куюо өчен җайланма белән урман җәнлекләре сыннары да, журнал, күчереп йөртә торган өстәлләр дә һәм тагын бик күп әйберләр бар. Саный китсәң, барлык ясаган әйберем биш йөзгә җыеладыр, ди ул.

Материалларны урманнан ала. Озын-көзен, кышын. Җәйлы эш түгел ул. Әмма буш кул белән кайтканын хәтерләми Атлас Солтанов. «Табигать – минем стихиям», – ди ул. Моннан тыш ул әле балыкчы да, тимердән төрле әйберләр ясау остасы да, рәссам да, спортчы да. Ветераннар арасында үткәрелгән республика спартакиадасында ату буенча призлы урыннар яулап кайткан. «Бу шөгылем миңа күңел, җан тынычлыгы бирә. Хыялларым күп, аларны тормышка ашырасым бар әле», – ди ул.

Гөлсинә ЗӘКИЕВА